**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25» сентябрь 2024 ел № 16

«Иске Дөреш авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын сүндерү чараларын тәэмин итү турында» Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 декабрендәге 28/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 276-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 декабрендәге 454-ФЗ номерлы (2021 елның 21 декабрендәге үзгәрешләр белән) Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Иске Дөреш авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын сүндерү чараларын тәэмин итү турында» Иске Дөреш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 декабрендәге 28/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлек үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 4.6 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 4.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Янгын куркынычы арткан очракта, махсус янгынга каршы режим урнаштыру буенча:

- янгын куркынычсызлыгы буенча муниципаль норматив хокукый актлар белән янгын куркынычсызлыгы буенча өстәмә, шул исәптән торак пунктлар чикләреннән читтә янгыннарны профилактикалау һәм локальләштерү өчен халыкны җәлеп итүне күздә тота торган таләпләр билгеләү,
- гражданнарның урманнарга баруын тыю, урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннар, шулай ук торак пунктлар чикләреннән тыш башка янгыннар таралуга каршы өстәмә чаралар күрү (торак пунктлар чикләре буенча янгынга каршы өзеклекләрне арттыру, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыру һәм шундый чаралар).».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.М. Дусадбеков